СӨЯ ГОМЕРНЕ, СӨЯ ХАЛЫКНЫ, СӨЯ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫНЫҢ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

Газета 1931 елның я июленнән бирле чыга. | №55 (7228) | 16 май, 1991 ел. ПӘНҖЕШӘМБЕ | Бәясе 4 тиен.

## «Чәчү-91» пресс-үзәге хәбәр итә

Соңгы көннәрдә һава торышының бозылуы кыр эшләре барышына шактый тоткарлык ясады. 15 майга районда 35239 гектарда сабан культуралары чәчелде. Бу—барлык мәйданның 63 проценты дигән сүз. Азык культуралары чәчелә торган мәйданның 1566 гектарында сусыз аммиак белән эшкәртү үткәрелде. Чәчүлекләр шытканчы 4997 гектарда җир тырмаланды, шытымнар буенча 400 гектарда тырмалау башкарылды.

Хуҗалыклар хәзер шикәр чөгендере чәчү белән мәшгульләр. Ул эш 855 гектарда үтәлде. «Восход», Синдряков исемендәге, «Большевик», «Лесная поляна» колхозлары, «Рассвет» совхозы, хуҗалыкара берләшмә кукуруз чәчәләр.



Таныш булыгыз: сезнең алда «Төрнәс» совхозы механизаторы Николай Васильевич Денисов.

Быел яз ул 610 гектар мәйданда кыр эшләре башкарды, шуның 330 гектарында чәчү үткәрде. Башкарылган эш күләме буенча Николай совхозда беренче урында бара. Бүгенгесе көндә алдынгы кыр эшчәне совхоз басуларында арпа чәчә, көнлек нормасын күпкә арттырып үтәп, хезмәттәшләрен ярышта әйдәп бара.

## Җиңүчеләр билгеләнде

КПСС райкомы, халык депутатларының район Советы башкарма комитеты, АПК работниклары профсоюзы райкомы президиумы һәм ВЛКСМ район комитеты бюросы апрель аенда колхоз-совхозлар арасында терлекчелек продукциясе җитештерү буенча социалистик ярыш нәтиҗәләрен карады.

Апрель аенда бер сыерга 384 килограмм сөт җитештергән «ҮРНӘК» колхозы ярышта җиңүче дип табылды.

Бу айда узган ел белән чагыштырганда һәр сыерга уртача савымны 35 килограммга арттырган «Знамя Октября» колхозы иң зур үсешкә иреште.

Бу хуҗалыкларга КПСС райкомы, халык депутатларының район Советы башкарма комитеты, АПК работниклары профсоюзы райкомы һәм ВЛКСМ райкомының күчмә Кызыл байраклары тапшырылды.

Карарда сөт җитештерү һәм үсешне арттыруда «Заря», «Большевик», «Родина» колхозларының әйбәт эшләве билгеләнде, ә бу айда узган елның шул чоры белән чагыштырганда продукция җитештерүне 101—81 килограммга киметкән «Россия», Хафизов исемендәге колхозлар һәм «Сөлчә» совхозы тәнкыйтьләнде.

● **Һәркемне борчыган тема**

## Сузмаска иде

Кулларына талон алгач, шәһәр халкы бермәл җиңел сулыш алып куйган иде. Ярар, тиешлесен булса да чиратсыз-этешсез алырбыз ичмаса, дигән иде. Әмма күз алдыгызда: чират та кимемәде, аның өстенә йөгерү дә өстәлде. Эш шунда: февраль аеннан талоннарны реализацияләү нигезендә эшчеләрне тәэмин итү бүлекләре (ОРС) кибетләренә йөкләнде, райпода 3600 кешегә хезмәт күрсәтү генә калдырылды. Бу үзе безгә аңлатуларынча, изге нияттән дә башкарылган булган икән: дәүләт сәүдәсендә тәэминат бермәбер ышанычлы, аннан товарлар алу җиңелрәк, отышлырак. Әмма хәл уңай якка үзгәрде дип кем әйтә ала? Шулай булганда, аннан кемгә файда?

—Безгә түгел,—диләр райпо җитәкчеләре.—Товар әйләнеше кимеде, план үтәлми.

—Безгә дә түгел,—дияр иде гарык булган сатып алучылар. Бердән, шәһәрнең 4 почмагыннан талон тотып Кормыш поселогына күпме йөгерергә була, ә бит талоннар нигездә шул кибетләрдә реализацияләнә. Ярар иде әле аны бер баруда тулысынча башкара алсаң. Я ярмасы юк, я—шикәр комы. Инде була калса—очсыз-кырыйсыз чират, этеш. Әнә талонга бер сортлы он сатканда милиция хезмәткәрләрен китереп бастырырга мәҗбүр булдылар хәтта. Шул арада кибетчеләр дә «үзешчәнлек» күрсәтеп алырга иренмиләр: ике янәшә кибетнең берсендә калган апрель талоннарына продукция бирмиләр. Я булмаса бер кулга ике генә талонга әйбер саталар (ишле гаиләләргә 4 әр чират торасы, күрәсең). Талонга җибәреләсе продукция керүгә карап сәүдә формасын үзгәртергә, аны тизләтергә дә бик ашыкмыйлар. Кыскасы, болай да ачулы халыкның түземе белән уйнапмы уйныйлар.

—Талоннарны реализацияләүне үзәк кибетләргә күчерсеннәр иде.

—Продукция даими киштәләрдә тормаганда, үткән ай талоннарын да реализацияләсеннәр иде,—дип мөрәҗәгать итәләр сатып алучылар безгә.

Без шул сүз белән райпо идарәсе рәисе Һ. Х. Садыйковка мөрәҗәгать иттек.

—Бу мәсьәлә район советы президиумында каралды,—диде ул безгә җавабында.—Безгә июнь аеннан фондны күчереп, элекке тәртипкә кайтырга күрсәтмә бирелде. Республикада бу мәсьәләне хәл итү сузылмаса...

Сузыла күрмәсен иде! Юкса, чиратның бер очы турыдан-туры дәрәҗәлерәк ишекләргә сузылуы бик ихтимал бит.

## Планнар үтәлә

Районның халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү производство идарәсе коллективы 1991 елның дүрт ае планнарын 104,8 процентка үтәде.

Коллективның яхшы күрсәткечләренә чәч тараш цехыннан Инесса Етриванова һәм фотога төшерү цехыннан Валентина Никонорова җитәкләгән бригадалар зур өлеш кертәләр.

**Н. МАРКОВА,**
экономист.

x x x

Норлат трикотаж ательесы җиткерелгән планны даими арттырып үтәве белән аерылып тора. Ателье 4 айга җиткерелгән 122.600 сум урынына 137.400 сумлык товар реализацияләде. Халык алар бәйләгән әйберләрне бик яратып ала.

Бәйләүче Кадрия Кыямова, Миләүшә һәм Гөлкәй Җәлаловалар, тегүче моторист Вера Зюзляева, Зинаида Сидорова бик тырышып эшлиләр. Алдынгылар исәбендә өйдә эшләүчеләр исемнәрен дә атыйсы килә. Фәүзия Сафина—арада иң уңганнардан. Ул «Верена» журналы буенча заманча фасонлы киемнәр бәйли, аңа һәрчак заказлар күп була. Шуңа бәйләүче һәр айда планны 120 шәр процентка үтәп килә.

**Л. КАБАНОВА.**

## Мөмкинлекләрне барлап

Җәйге чор—арзанлы терлекчелек продукциясе җитештерү өчен иң кулай вакыт. Еллык продукциянең 53—57 проценты нәкъ шушы айларда, җәмәгать малларының җәйләү чорында җитештерелә. Шуңа да бу вакытка колхоз-совхозларда җәйге лагерьларны заман таләпләренә туры китерерлек итеп әзерләү, терлекчеләр өчен эш шартларын тудыру бик мөһим.

Район хуҗалыкларының күбесендә аның әһәмиятен аңладылар инде. Байтак хуҗалыкларда хәзер типовой лагерьлар бар, алар малларны кабул итүгә бүгеннән әзер. «Кондырча», «Татарстан», «Путь к коммунизму», «Таң», «Заветы Ильича», «Комбайн» колхозлары, «Рассвет» совхозы һәм Кузнецов исемендәге колхозлар—нәкъ шундый хуҗалыклар. Биредә терлекчеләр өчен байтак шартлар тудырылган: универсаль сөтүткәргеч куелган, савым механик юл белән үткәрелә, суыту җайланмалары һәм сөт лабораторияләре көйләнгән. Малларны җәйге чорда асрау өчен чаралар планы расланган, яшел конвейерны өзлексез эшкә җигү дә каралган. Әлеге аталган хуҗалыкларда кадрлар мәсьәләсе дә кыенлыклар тудырмый, алар даими савучылардан тупланган, алмаш савучы мәсьәләсе дә хәл ителгән. Терлекчеләр өчен ял урыны, тамак ялгау мөмкинлеге дә һәрьяклап уйланылган. «Кондырча», «Заветы Ильича», XXI партсъезд исемендәге, Ульянов исемендәге колхозларда лагерьларда бозаулату бүлекләре дә булдырылган, анда шартына туры китереп индивидуаль читлекләр дә ясалган. Бу җәй көнне дә сәламәт үрчем алу өчен шартлар тудыра. Җәйге лагерьлар булдыруның тагы бер өстенлеген дә әйтергә кирәк. Маллар җәйләүдә булганда, терлекчелек биналарын җентекләп карау, ремонтлау өчен мөмкинлек туа. Бу, үз чиратында, кыш көне продукция муллыгына ирешүдә уңай йогынты ясый.

Мөгезле яшь эре терлекләрне җәйге лагерьларда тоту тәҗрибәсе дә күп хуҗалыкларда ныгыды инде. «Игенче», «Комбайн», «Татарстан» колхозларында, «Рассвет» совхозында яшь терлекләрне тулысынча лагерьларда асрыйлар. Биредә алар өчен түбәсе ябылган бина, азык улаклары булдырылган, су, минераль өстәмәләр белән тәэмин итү дә әйбәт куелган. Терлекчеләр йортлары—будкалар яки вагончыклар булдыру турында да алдан кайгырту күрелгән. Шуның нәтиҗәсендә әлеге хуҗалыклар җәйге чорда артым алуны 700 граммнан да киметмиләр, үрчемнең тулысынча саклануына да ирешәләр.

Безнең районда дуңгызлар өчен лагерьлар оештыру, кызганычка каршы, киң кулланышка кермәгән. Әмма «Россия» колхозы бу мәсьәләдә якыннан торып шөгыльләнә һәм бермә-бер ота. Биредә ана дуңгызлар лагерьда асралалар. «Төрнәс», «Рассвет» совхозлары, Хафизов исемендәге колхоз терлекчеләре дә бу алымның отышлы булуына үз тәҗрибәләрендә инандылар инде.

Әмма хәл һәр җирдә дә бертөрле түгел. Быелга кадәр Муса Җәлил исемендәге, «Москва», «Үрнәк» колхозларында, «Заветы Ильича» колхозының Зүзәй фермасында, «Алга» колхозының 1 бригадасында җәйге лагерьлар юк, әлеге хуҗалыкларда мөгезле яшь терлекләр өчен лагерьлар булдыру турында да җитди уйлаучы юк. Ә бит бу мөмкинлекне файдаланмыйча, алар бик күп нәрсә оттырганнарын аңламыйлар. Быел бигрәк тә. Агымдагы елның 4 аенда районда бер сыерга сөт җитештерү узган ел белән чагыштырганда 122 килограммга кимрәк. Җәйләү чорында өзлексез яшел конвейер, минераль өстәмәләр һәм җитәрлек күләмдә су белән тәэмин итү бәрабәренә без шул аерманы бетерергә тиешбез. Моның өчен бүгеннән җәйге мөмкинлекләрне тулысынча эшкә җигү турында уйланырга, терлекчелекне даими кадрлар, алмаш савучылар белән тәэмин итәргә кирәк. Бу чорда малларга раздой оештыруны да күз уңыннан ычкындыру ярамый. Яшел конвейер, азыкларны төрләндерү, өстәмә рәвештә силос, сенаж бирү исәбенә продукция алуны арттыру иң төп ахыр максат булып калырга тиеш.

**Х. ФӘТХУЛЛИН,**
авыл хуҗалыгы һәм азыктөлек идарәсе зоотехнигы.

## Тәэсирле булды

9 май көнне Киекле авылында Бөек Җиңүгә багышланган тантаналы митинг булды.

Колхозның партоешма секретаре Н. Гатауллин тантананы ачып, сугыш һәм хезмәт ветераннарын, авыл халкын бөек бәйрәм белән котлады.

Укытучы Х. Шәмсуаров чыгышында авыл халкының да бу җиңүгә фидакарь хезмәте белән зур өлеш кертүенә басым ясалды. М. Могайнетдинов тәкъдиме буенча яу кырында башын салган авылдашларны бер минут тын калып искә алу булды.

Тантананы йомгаклап, колхоз рәисе В. Даутов ветераннар—ирләре сугыштан кайтмаган тол калган аналарны бәйрәм белән котлады, аларга истәлекле бүләкләр тапшырды.

**Г. ГЫЙЗӘТУЛЛИН.**

# Икмәк хакы шулай куша

—Егетләр соңгы гектарларда чәчәләр инде. Аннан чөгендер һәм кукуруз гына кала.

Ызан башына якынаеп килүче агрегатка карап, Фәргать Гайнуллин шулай дип куйды. Ул орлык ташый, шуңа да механизаторлар эшеннән хәбәрдар. Әнә бүген Вәгыйзь Ибәтуллин агрегатына хезмәт күрсәтә. Вәгыйзь—Салих Гомәровның аренда звеносыннан, коллективта икенче ел эшли инде. Быел звено аеруча әйбәт хезмәт куя. Техника җиренә җиткереп көйләнгән иде, башка еллардагы кебек орлык китерүдә дә тотарлыклар булмады. Шуңа да Гомәровнықылар бөртекле культуралар чәчүне хуҗалыкта беренче булып тәгәлләделәр, инде менә М. Бакиров звеносында ахыр эшләрне үткәрүдә булышалар. Вәгыйзь чәчүчеләре Нурислам Ишниязов Фәрит Әюпов, Салих Нигъмәтуллин белән азык катнашмалары участогын тәгәлләп килә. Кыска ял арасында ел үзенчәлекләре турында сөйләшәбез.

Чәчүгә оешкан төстә кереште «Кондырча» колхозы. Механизаторларның җитештерүчән эшләве өчен барлык шартлар каралган иде, хезмәткә түләү мәсьәләсенә дә үзгәреш кертелде, ашау-эчүне дә бер дигән оештырдылар. Әмма җирләрнең соң өлгерүе механизаторларны интектерде дә куйды. Хәзергә хәтле участокларда эшне сайлап үткәрделәр, бер кырдан икенче кырга маневр ясап кына тордылар. Бу, әлбәттә, кәефкә дә, эш темпына да сугасы иде. Әмма тупланганлык коткарды. Механизаторлар төшенкелеккә бирелмәделәр, берберартлы килгән бәйрәмнәр һәм ял белән дә исәпләшмәделәр—эш дәвам итте. Чәчү сыйфатлы итеп, тамырдан ашлама кертеп алып барылды, шунда ук катоклау да үткәрелде. Инде менә нәтиҗәсе — колхоз районда алдынгылар рәтендә бөртекле культуралар чәчүне тәгәлләп килә. Биредә, әлбәттә, Ибәтуллиннар өлеше дә аз кермәде. Вәгыйзь—алтын куллы механизатор. Урак чорында ул комбайнга утырачак. Үткән ел да ул хуҗалык комбайнчылары арасында беренче урынны алган иде. Быел да сынатмаска исәбе. Игене генә уңсын да, көннәре генә торсын— игенче үскәнне җыярга иренәме соң? Быел чәчүдән чыгып исәпләгәндә, кондырчалылар янә уңышка исәп тотарга тиешләр төсле дә бит. Икенче кырда язгы бодай чәчүче Фәрит Абдуллин егетләре дә сүзне шуннан башладылар. Болар— Минияр Бакиров звеносыннан. Орлык ташучы Сәгыйть Шәрифуллович Тәмаев та, аренда члены тракторчы Хафиз Халитов та шулай уйлыйлар. Фәритнең йнде ел үзенчәлеге турында фикер йөртерлек кенә тәҗрибәсе, шөкер җитәрлек. 20 нче ел механизатор булып эшли, арендада эшләвенә дә 4 нче ел китте. Сыйфат мәсьәләсендә хилафлык итүнең нәрсә белән бетәсен аңа аңлатып торасы юк. Шуңа да бик тырышып эшлиләр. Быел аның чәчүчеләре—СПТУның 1 нче курсы укучылары Дәнис Ильмухин һәм Ранис Тәмаев. Егетләр тәҗрибәле механизатор йөзен кызартмаска тырышалар.



Хәер, сыйфат мәсьәләсен болай гына бәяләү гадел булмас иде әле. Чәчү тәгәлләнгәч, махсус комиссия чәчүлекләрне карап нәтиҗәне үзе ясаячак. Шунда билгеле була инде кемнең ничек эшләве. Хәер, анысы шытымда гына чагылып калмаячак, уңышта да билгеле булачак. Кондырчалылар моңарчы оттырганнары булмады. Узган ел да бөртеклеләрнен һәр гектарыннан 30,7 центнер уңыш алганнар иде алар, быел дә ниятләре зурдан. Игенчеләр үзләреннән торганны һичшиксез үтәячәкләр, елы килсен дә һавасы гына уңай булсын инде. Соңгысы бу көннәрдә һәммә кешене борчуга салып тора әле. Түбән Норлатта да чөгендер чәчәргә керешкән иделәр — эш тукталды, кәеф төшебрәк торды. Ләкин бер нәрсә бәхәссез: көннәр үзгәрүгә, игенчеләр элеккечә үк активлык, оешканлык белән кырга чыктылар. Икмәк хакы шулай куша.

С. ХӘЙРУЛЛИНА.

**Рәсемдә: «Кондырча» колхозы механизаторы В. Ибәтуллин.**

# Гаделлек эзләгәндә...

**Авыл халкының алданган, күп нәрсәдән мәхрүм ителгән булуы турында сүзләр еш яңгырый. Дөрес сүзләр бу. Әмма алар ни өчендер үткән заманда гына кулланылалар. Әйтерсең лә, аларга мөнәсәбәт тамырдан үзгәргән, әйтерсең лә, бүгенге авыл халкы—терлекче, игенче бездә көн батырлары, һәм аларга хөрмәт тә, данлау да, махсус тәэмин итү дә бар. Әмма чынлыкта шулаймы соң бу?**

—1989 елда планнан тыш ашлык тапшырган өчен СССР Министрлар Советы карары белән безнең хуҗалыкка өч «Жигули» машинасы, бер УАЗ һәм ике «УРАЛ» мотоциклы сатып алу хокукы бирелгән иде. Шунда ук идарә утырышы җыелды һәм бу техниканы алдынгы механизаторларга бирергә дип карар чыгарды. Машиналарны без алдык, ә мотоциклллар белән тоткарлык килеп чыкты. Казанга ике тапкыр махсус кеше җибәрдек. Һәм ниһаять безгә: «Мотоцикллар Бөгелмә сәүдә базасы аша Октябрь райпосына кайтарылдылар»,—дигән хәбәр булды. Ә бу вакытта инде аларны сатучы Сания Котдусова үзенең улларына алып бирергә өлгергән булып чыкты.

«Чишмә» колхозы рәисе Х. Х. Шәйхетдиновның шушы хикәятләрен ишеткәннән соң, әлеге вакыйгага катнашы булган кешеләргә мөрәҗәгать иттек. Беренче әңгәмәдәшебез —райпоның яңа рәисе Һ.Х. Садыйков булып чыкты. Әмма аның сүзләре вакыйгага бернинди ачыклык кертмәде:

—Мин 21 январьдан башлап ялда булдым. Шуңа күрә бу хакта белмәдем. Бу хәлләр миңа колхоз рәисе шалтыраткач кына мәгълүм булды. Эш кәгазьләрен күтәрергә мәҗбүр иттем һәм шунда гына мотоциклларны С. Котдусова алганлыгы ачыкланды.

Промторг директоры Камил Гафуров сүзләре мәсьәләгә бераз ачыклык өстәде. Чөнки әлеге мотоциклларны Бөгелмә сәүдә базасыннан алып кайту өчен «Йорт-бакча» кибете мөдире С. Котдусовага ышаныч язуын нәкъ менә ул биргән. 23 январьда инде әлеге техника Норлатка кайтарылып «Йорт-бакча» кибетенең склад бинасына бушатып та куелган. Озакламый, Гафуров әйтүенчә, мотоциклларның берсе «юкка чыккан». Ул бу хакта белешеп сатучыга мөрәҗәгать иткән. Аңа ул вакыттагы райпо рәисе М. М. Сафин боерыгы буенча әлеге мотоциклның билгесез бер кешегә сатылганлыгын әйткәннәр. Икенче мотоциклның да сатылу тарихын шулай аңлаталар.

Шушы ишеткәннәрдән соң берничә сорау бирәсе килә. Нишләп соң «Йорт-бакча» кибетенә тиеш булмаган төрдәге товарны алу өчен нәкъ менә Котдусова җибәрелгән? Ни өчен мотоцикллар «Техника» кибетенә бушатылмаганнар һәм керемгә алынмаганнар?Һәм ничек инде мотоцикллларның кайтарылуы турында аларның законлы хуҗаларына хәбәр ителмәгән? (Монда бернинди дә ялгышу юк, чөнки фактура кәгазендә акка кара белән: «Мотоцикллар «Чишмә» колхозы колхозчыларына җибәреләләр»,—дип язылган булган). Сораулар, әлбәттә, җавапсыз калды.

Дөрес, Сания Котдусова монда зур «кош» түгел. Райпоның элекке рәисе М. М. Сафин рөхсәтеннән башка ул алса савыт белән буяу, тартмасы белән порошок кына ала алыр иде, әмма һич тә мотоцикллар түгел. Бу хәлләр хакында урындагы башка җаваплы кешеләрнең дә белми калуы бик икеле. Мотоцикл энә түгел ләбаса. Һичшиксез белгәннәр дә, күргәннәр дә. Әмма берсе генә дә идарә рәисенә каршы чыгып сүз әйтә алмаган, хәтта телефонны алып колхозга шалтыратырга да көчләре җитмәгән.

Сания үзе, әлбәттә, бу бу эшнең «чиста» түгеллеген аңлаган, әмма артында ышанычлы терәк тойган хәлдә бик оператив эш иткән. Акча түләнгән, мотоциклларны сатып алып кына калмаганнар, уллары исеменә тиешенчә рәсмиләштереп тә куйганнар.

Шулай да булсын. Ә монда минем кешеләрчә, чын йөрәктән шуны гына әйтәсем килә. Чәчү яки урып-җыю чорында механизаторларның йокысызлыктан, киеренкелектән кызарган күзләренә бер тапкыр караган, аларның талчыгудан чайкала төшеп эңгер-меңгердә өйгә кайтканнарын һәм арыганлыктан алдында торган ашны да кабарга өлгермичә өстәл артында йокыга талганнарын бер генә тапкыр булса да күргән кеше мондый гаделсез адымны ясый алмас иде.

Хәзерге вакытта райпо җитәкчелеге яңартылды, әмма идарә системасы шул килеш калды: җитәкче сүзе—аның кул астындагылар өчен закон һәм монда сүзнең намус белән, гадәти кешелеклелек белән бәрелешүе бернигә дә тормый. «Чишмә» колхозы механиторлары үзләренең редакциягә язган хатларында: «Гаделлек кая?— дип сорыйлар. Чынлап та, каян эзләргә икән аны?

Г. ХӘЛИУЛЛИНА.

# Имче әби

Минсафа әби авылда гомерлек кендек әбисе иде.

—Минсафа әби, тизрәк, син кирәк. Фәлән хатынны тулгак тота,—дип йөгереп килеп керерләр дә әбине җилтерәттереп алып та китәрләр иде. Аннан инде бәби көткән хатын янында әби генә кала. Аның кичерешләрен кичереп, авыртуларын җиңеләйтер өчен кулдан килгәннәрнең һәммәсен ул башкара. Һәм менә бисмилласын әйтеп, кулына яңа туган баланы ала, аның беренче авазын ишеткәч:

—Шөкер, исән-сау дөнья күрдек. Бәхетең-тәүфигың белән кил,—дип, әбилек вазифасының башка өлешен башкарырга керешә.

Һәр шундый көннән Минсафа әби яшәреп киткәндәй була иде. Әбинең җил-җил атлап урамнан кайтуын күргән авылдашлар нәтиҗәне шунда ук ясап калалар:

—Минсафа әби кайта. Исән-сау котылган булыр фәләннең хатыны.

Әби 200 ләп бәбигә кендек әбисе булды. Ул заманнарда авылдагы төп «акушер-гинеколог» булып шундый әбиләр яши иде бит инде.

Шөкер, балалар да үлмәде, хатын-кызлар да сәламәт булды. Әби дә өлгерде. Әллә гел йөгереп йөргәнгә шулай озын гомерле булгандыр да әле. Әнә бит, үзе әйтүенә караганда 98 яшендә инде. Әле галошын киеп, медпунктка да барып кайта, күршегә дә кереп чыга. Норлатка кызына җәяүләп бармый башлавы да соңгы елда гына булды. Аңа кадәр таягына таяна да китә иде җил-җил атлап! Җиңел сөякле булды Минсафа әби. 80 не тутырганчы колхоз эшендә исәпләнде, иренмәде.

—Кешене эш бетермн, кешене кайгы бетерә, —диярргә ярата иде ул. Юкса, кайгысын да кичермәде түгел Минсафа әби. Ире, малае үлде, бар чагыннан юк чагы күбрәк булды. Әмма төшенкелеккә бирелмәде. Хәер, нәрсә дип боларны бөртекләп сөйләп торам соң әле? Әйтерсең, Минсафа әбине Кормыш авылында белмиләр? Беләләр, әлбәттә. Кормышта гына түгел, тирә-як авылларда да, Норлатта да әйбәт беләләр аны. Әле хәзер дә аңа һәр көнне 2—3 кеше килеп тора. Чөнки ул—имче әби дә.

Кулыгызны яки тәнегезне сөял бастымы? Минсафа әби аның имен белә. Кешенең үзе буе җеп ала да, сөял өстенә куеп, әлһәм, салават укып төенли. Тагын нәрсәләрдер эшли. Боларны ул чәршәмбе көнне башкара. Пәнҗешәмбе көнне иртән уянган җиргә сөялләрегезне күрмәвегез бик ихтимал. Чуан чыгып җәфаласа да дәвасы бар, күз тиеп сыткыфәлән чыкса да әби имли. Тимерәүне дә сыза. Бала куркынып кала икән— аны да шундук әбигә алып килләр. Ул куркулык яки чарпы коя. Әбинең «докторлык» тәҗрибәсендә әллә нинди очраклар, әллә нинди гыйбрәтләр бар.

Норлаттан бер хатын-кыз яшь баласын алып килә. «Тавыштан да курка»,—ди. Куркулык коялар—лампочка сурәте төшә. «Шулай, электр утын кинәт кабызгач куркынган иде»,—ди хатын бу туры килүгә исе китеп. Баланы дәвалыйлар. Хәер, куркынган авыруларны бик күпләп тынычландырырга, дәваларга туры килә әбигә.

—Ихлас күңелдән дәвалаганга, аннан үзем сырхаулаган чаклар да күп була,—ди ул. Элек аңа кызамык, чәчәк ише авыруларны да дәваларга туры килгән.—Аларның хуҗалары бар,—ди әби. Күрәсең, боларының дәвасы үзенә бер төрледер, әби әйтеп бетерми.

Үзе янына килгәннәрне сорашып-белешеп кала, сөйләшергә иренми әби. Табиплар үпкәләмәсеннәр, әби янына туры шифаханәдән больница халатыннан килүчеләр да бар икән. Чит өлкәләрдән дә киләләр, әби прописка сорамый. Бер ир-ат Ульяновск шәһәреннән кадәр килгән. Тыны кысудан интеккән булган. Соңгы килүендә шифасы булуын әйтеп, бик матур күлмәк вәгъдә итеп киткән.

(Ахыры 4 нче биттә).

